ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

КАРАР № 21

Урыссу штб 19 сентября 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 елның 82 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 26.12.2008 елның № 294-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 елның №82 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 статьясындагы 4.10.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10.3. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ санлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин